# КАРАР

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы “Арча шәһәре” муниципаль берәмлегенең Күпербаш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**2025 елның 20 ноябре** **№ 4**

“Ачык хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2025 елның 14 ноябрендә узган түбәндәге мәсьәлә буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе төзелде:

“2026 елда Арча муниципаль районының Күпербаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 300 сум күләмендә үзара салым акчасы җыюга, 1 төркем инвалидлар, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш, алар өчен түләү күләме 100 сум тәшкил итә, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (контракт, мобилизация буенча һәм ирекле хәрби хезмәт итүчеләрне) һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче әти-әниләрен, хатыннарын, балаларын) түләүдән азат итүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә сез ризамы?”

- Күпербаш авылы урамнарында юл өслеген түшәү катламы ясау?

Гражданнар җыены беркетмәсе (йомгаклау беркетмәсе) нигезендә:

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 322 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 169 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

“Әйе” позициясе өчен гражданнар җыенының 90 катнашучысы тавыш бирде;

“каршы” позициясе өчен җыенның 79 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Арча шәһәре” муниципаль берәмлегенең Күпербаш авылында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. “2026 елда Арча муниципаль районының Күпербаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 300 сум күләмендә үзара салым акчасы җыюга, 1 төркем инвалидлар, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш, алар өчен түләү күләме 100 сум тәшкил итә, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (контракт, мобилизация буенча һәм ирекле хәрби хезмәт итүчеләрне) һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче әти-әниләрен, хатыннарын, балаларын) түләүдән азат итүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә сез ризамы?

- Күпербаш авылы урамнарында юл өслеген түшәү катламы ясау?” мәсьәләсе буенча карарны

кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәсен түбәндәге адрес буенча мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: ТР, Арча районы, Күпербаш авылы, Мичурин урамы, 10 йорт, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында: http://arsk.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

“Арча шәһәре” муниципаль
берәмлеге башлыгы — А.Г.Хисаметдинов